**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЧЕРЕМШАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

**Улица М.Титова, дом 7,
Черемшан село, 423100**

**М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән
авылы, 423100**

**тел./факс 8(84396)2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru**

**№ 60** **13 май 2022 ел**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 20 сентябрендәге 98 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 сентябрендәге 98 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына (2018 елның 17 декабрендәге 154 номерлы, 2019 елның 15 мартындагы 165 номерлы, 2021 елның 28 сентябрендәге 35 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларын яхшырту, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итү һәм яхшырту, торак пунктларның территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән, муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру буенча эшчәнлек»;»

1.2. 125 пунктның 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сәүдә һәм

җәмәгать туклануы предприятиеләрен, шул исәптән палаткалар, киосклар, ларeклар, мини-базарлар, павильоннар, җәйге кафелар, җитештерү объектларын, автомобильларны, көнкүреш техникасын, аяк киемен вак-төяк ремонтлау предприятиеләрен, шулай ук кунакханәдән кала автостоянкаларны урнаштыру.

Тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләренең милекчеләре, Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, аларга стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында карар кабул итәләр.».

1.3. 183 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « хайваннар авыруларын кисәтүне һәм хайваннар продукциясенә ветеринария - санитария мөнәсәбәтендә куркынычсызлыкны тәэмин итүче хуҗалык һәм ветеринария чараларын гамәлгә ашыру, әйләнә-тирә мохитнең терлекчелек калдыклары белән пычрануына юл куймау, шулай ук ел саен яңадан теркәлү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактика чаралары үткәрү»;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (pravo.tatarsnan.ru) һәм мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Чирмешән авыл җирлеге

башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин